# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ

# КАРАРЫ

**№1** **10.11.2023 ел.**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Чемодурово авыл җирлеге составына керүче
Алферовка авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131 ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Сез, 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Алферовка авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә,1 нче группа, 2 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзалары булган гаиләләрдән кала, бер тапкыр түләүне киметеп, 250 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә ризамы:
- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту.

“РИЗА” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 20 кеше кертелгән, 17 кеше тавыш бирүдә катнашкан.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:
"Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 17 кеше тавыш бирде;
җыенда катнашучы 0 «юк» позициясе өчен тавыш бирде.

1. Азнакай муниципаль районының Чемодурово авылында халык җыены үткәнен, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип тану.

«Сез, 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Алферовка авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган

һәр кешедән 500 сум күләмендә,1 нче группа, 2 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзалары булган гаиләләрдән кала, бер тапкыр түләүне киметеп, 250 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә ризамы:

- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырыга: http//aznakayevo.tatar.ru һәм Алферовка авылы, Зеленая урамы , 5 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык А.П.Курганская